МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

24.02.2021 Казан шәһәре №58

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмә раслау хакында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы Указы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләү һәм дәүләт органнары кадрлар резервына кертү буенча конкурслар уздыруның бердәм методикасын раслау турында» 2018 елның 31 мартындагы 397 номерлы карары, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервы турында нигезләмә раслау турында» 2011 елның 14 мартындагы ПУ-127 номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүче гражданнарга тест уздыруны оештыру мәсьәләләре» 2015 елның 11 декабрендәге ПУ-1192 номерлы Указлары нигезендә, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә һәм нәтиҗәле кадрлар резервын формалаштыруга кандидатларны сыйфатлы сайлап алу максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында кушымтада бирелгән нигезләмәне (алга таба – Нигезләмә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының конкурс комиссиясендә өч елдан артык булган бәйсез эксперт үз вәкаләтләрен 2021 елның 1 июленә кадәр саклый дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмә раслау турында» 2018 елның 19 июлендәге 358 номерлы боерыгын гамәлдән чыккан дип танырга.

4. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә (В.Р. Садыйкова) Нигезләмәгә туры китереп, дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурслар оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

**Татарстан Республикасы**
**Премьер-министры урынбасары –**
**министр** **М.Р. Шаһиәхмәтов**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрының
24.02.2021 № 58 боерыгы
белән расланды

## Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмә

### I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Нигезләмәдә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру буенча конкурс комиссиясенең (алга таба – конкурс комиссиясе) эшләү вакытлары һәм тәртибе, шулай ук Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында (алга таба – конкурс, Министрлык) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру методикасы билгеләнә.

Конкурс Россия Федерациясе гражданнарының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенә (алга таба – граждан хезмәте) тигез дәрәҗәдә үтеп керүенең конституциячел хокукын, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – граждан хезмәткәрләре) конкурс нигезендә вазыйфада үсү хокукын тәэмин итә.

1.2. Министрлыкта Конкурс «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – Федераль закон) 22 статьясы һәм «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы Указы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә һәм дәүләт органнарының кадрлар резервына кертүгә конкурслар үткәрүнең бердәм методикасын раслау турында» 2018 елның 31 мартындагы 397 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясенең дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар хезмәтенә мәгълүмат технологияләрен кертүнең кайбер чаралары турында» 2018 елның 5 мартындагы 227 номерлы карары, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенә кадрлар резервы турында нигезләмә раслау турында» 2011 елның 14 мартындагы ПУ-127 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүче гражданнарга тест уздыруны

оештыру мәсьәләләре» 2015 елның 11 декабрендәге ПУ-1192 номерлы Указы нигезендә уздырыла.

Конкурс Министрлыкта граждан хезмәте вакант вазыйфасын (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасын) биләү өчен дәгъва белдерүчеләрнең һөнәри дәрәҗәсен, аларның әлеге вазыйфага карата билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килүен бәяләү максатында уздырыла.

1.3. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс Федераль закон нигезендә конкурс нигезендә биләнергә мөмкин булган граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы булган очракта, икътисад министрының (аның вазыйфаларын башкаручы затның) (алга таба – министр) карары белән игълан ителә.

1.4. Конкурс дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге тарафыннан ел саен Министрлыкта граждан хезмәте вакант вазыйфаларын биләү өчен белгечләргә мөмкин булган ихтыяҗны һәм Министрлыкта булган кадрлар резервын бәяләү нәтиҗәләре буенча оештырыла.

Конкурс Министрлыкның конкурс комиссиясе тарафыннан әлеге Нигезләмәдә каралган тәртиптә уздырыла.

Министрлыкта конкурс оештыру «Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең һәм муниципаль хезмәтнең кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасыннан (алга таба – Кадрларның бердәм мәгълүмат системасы) файдаланып гамәлгә ашырыла.

1.5. Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс түбәндәге очракларда үткәрелми:

билгеле бер чорга биләнә торган «җитәкчеләр» һәм «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категориясендәге граждан хезмәте вазыйфасы вәкаләтләрен биләү өчен билгеләнгәндә;

ашыгыч хезмәт контракты төзелгәндә;

Федераль законның 28 статьясының 2 өлешендә, 31 статьясының 1 өлешендә һәм 60.1 статьясының 9 өлешендә каралган очракларда граждан хезмәткәрен дәүләт граждан хезмәтенең бүтән вазыйфасына билгеләгәндә;

граждан хезмәтендә кадрлар резервына кертелгән граждан хезмәткәрен (гражданинны) граждан хезмәте вазыйфасына билгеләп куйганда.

1.6. Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс түбәндәге очракларда үткәрелмәскә мөмкин:

алар буенча вазыйфаи вәкаләтләрне үтәү дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга бәйле булган, Министрлык боерыгы нигезендә раслана торган вазыйфалар исемлегендә аерым граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә;

министр карары нигезендә, граждан хезмәтенең кече вазыйфалар төркеменә карый торган граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә.

1.7. Конкурс үткәрелә торган максатлар:

Россия Федерациясе гражданнарының конституциячел хокукларын, аларның сәләтләре һәм һөнәри әзерлекләре нигезендә дәүләт граждан хезмәтеннән бертигез файдалану мөмкинлеген, шулай ук дәүләт граждан хезмәткәрләренең конкурс нигезендә вазыйфаи үсешкә хокукларын тәэмин итү;

граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен аеруча туры килә торган кандидатларны Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән таләпләргә җавап бирә торган һәм конкурста катнашуга кертелгән кандидатлар арасыннан сайлап алу;

Министрлыкның кадрлар резервын формалаштыру.

1.8. Конкурслар үткәргәндә хәл ителә торган бурычлар:

конкурс биремнәрен һәм процедураларны үтәгәндә барлык кандидатлар өчен тигез шартлар тәэмин итү;

кандидатларны граждан хезмәтенең мәдәниятенә, һөнәри вәкаләтлелеккә һәм шәхси-эшлекле сыйфатларга туры килү критерийлары нигезендә бәяләү;

Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасы) таләпләренә туры килә торган затларны конкурста катнашучылар арасыннан аларның конкурс биремнәрен үтәү һәм конкурс процедураларын үтү нәтиҗәләрен чагыштыру юлы белән ачыклау.

## II. КОНКУРС КОМИССИЯСЕ ТӨЗҮ ҺӘМ АНЫҢ ЭШЛӘҮ ТӘРТИБЕ

2.1. Министрлыкта конкурслар уздыру өчен министр боерыгы нигезендә Министрлыкның даими нигездә эшләүче конкурс комиссиясе төзелә. Комиссия составына кертелгән вазыйфаи затларның шәхси составы үзгәртелгәндә, министр боерыгы белән тиешле үзгәрешләр кертелә.

Конкурс комиссиясе эшенең объективлык һәм бәйсезлек дәрәҗәсен арттыру максатларында дәүләт органы җитәкчесе карары нигезендә аның составы ел саен яңартылып тора.

2.2. Конкурс комиссиясе рәисе, рәис урынбасары, сәркатип һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

Конкурс комиссиясе составына министр һәм (яки) ул вәкаләт биргән граждан хезмәткәрләре (шул исәптән, дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегеннән һәм граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздырыла торган бүлекчәсеннән), Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, шулай ук бәйсез экспертлар – тиешле өлкәләрдә һәм граждан хезмәткәрләренең һөнәри хезмәт эшчәнлеге төрләрендә кадр технологияләре һәм граждан хезмәте мәсьәләләре буенча белгечләр булып торган фәнни, мәгариф һәм башка оешмаларның вәкилләре керә.

Конкурс комиссияләре составына кертелә торган фәнни, мәгариф һәм башка оешмалар вәкилләре законнарда билгеләнгән тәртиптә, бәйсез экспертларның шәхси мәгълүматларын күрсәтмичә эшкә алучының вәкиле тарафыннан юлланган рәсми мөрәҗәгать буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан чакыртыла һәм сайлап алына. Конкурс комиссиясе составына кертелә торган Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет карарлары белән билгеләнә.

Бәйсез экспертның дәүләт органы конкурс комиссиясендә булуының гомуми вакыты өч елдан артмаска тиеш. Әлеге срок бәйсез экспертны конкурс комиссиясе составына беренче керткән вакыттан башлап исәпләнә. Әлеге бәйсез экспертны

конкурс комиссиясе составына кабат кертү Конкурс комиссиясендә булу срогы тәмамлангач өч елдан соң гына гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Бәйсез экспертның бер дәүләт органы конкурс комиссиясендә булуының вакыты җыеп исәпләгәндә өч елдан артмаска тиеш.

Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет әгъзаларының һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясендәге барлык әгъзаларының кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

2.3. Конкурс комиссиясенең рәисе аның эшчәнлегенә җитәкчелек итә, утырыш үткәрү көнен билгели, комиссия утырышларында рәислек итә һәм тиешле документларга имза сала.

Конкурс комиссиясе рәисе булмый торган чорда аның вазыйфаларын конкурс комиссиясе рәисе урынбасары үти.

Конкурс комиссиясе сәркатибе конкурс комиссиясенең эшен тәэмин итә (гаризаларны кабул итә, эшләрне формалаштыра, конкурс комиссиясе утырышлары карарларын рәсмиләштерә һ.б.).

2.4. Алар буенча вазыйфаи вәкаләтләрне үтәү дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга бәйле булган граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздырылганда конкурс комиссиясе составы Россия Федерациясенең дәүләт сере турында законнары нигезләмәләрен исәпкә алып төзелә.

2.5. Конкурс комиссиясе составы, конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителә торган карарларга йогынты ясый алырлык мәнфәгать каршылыклары барлыкка килү ихтималы булмаслык итеп төзелә.

2.6. Конкурс комиссиясе утырышы граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервына кертү өчен) кимендә ике кандидат булганда үткәрелә һәм, әгәр анда аның әгъзаларының гомуми санынннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала. Конкурс комиссиясе утырышын бары тик граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче әгъзалар катнашында гына уздыру рөхсәт ителми.

Конкурс комиссиясе тарафыннан утырышны аның әгъзасы яки кандидаты тәкъдиме белән, мондый карар сәбәбен (нигезен) күрсәтеп, видеоконференция форматында (техник мөмкинлек булган очракта) уздыру турында конкурс комиссиясе карары кабул ителергә мөмкин.

2.7. Конкурс комиссиясе карары кандидатның үзе булмаганда кабул ителә һәм аның ризалыгы яисә моннан баш тартуы нигезендә аны граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләү (кадрлар резервына кертү) өчен нигез булып тора.

2.8. Конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе карары ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучы әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, конкурс комиссиясе рәисе тавышы хәл иткеч була. Конкурс комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс йомгаклары буенча конкурс комиссиясе карары һәм кадрлар резервына керүгә конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

2.9. Конкурс комиссиясе шулай ук тәкъдим холкына ия булган, граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләү өчен конкурста җиңмәгән, ләкин һөнәри һәм шәхси сыйфатлары югары бәя алган кандидатны Министрлыкның кадрлар

резервына кертү турында карар кабул итәргә хокуклы. Күрсәтелгән кандидатның ризалыгы белән, ул Министрлыкның кадрлар резервына кертелергә мөмкин.

2.10. Конкурсны турыдан-туры оештыруны һәм уздыруны, конкурс комиссиясе эшен тәэмин итүне Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге гамәлгә ашыра.

## III. КОНКУРСТА КАТНАШУЧЫЛАР

3.1. 18 яшен тутырган, Россия Федерациясе дәүләт телен белгән һәм граждан хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләү өчен дәүләт граждан хезмәте турында Россия Федерациясе законнарына туры китереп билгеләнгән квалификация таләпләренә җавап бирә торган Россия Федерациясе гражданнары конкурста катнашу хокукына ия.

Граждан хезмәткәре конкурс уздырылган чорда үзенең нинди вазыйфаны биләвенә бәйсез рәвештә гомуми нигезләрдә конкурста катнашырга хокуклы.

3.2. Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) буенча кандидатларга карата таләпләргә җавап бирә торган һәм шушы Нигезләмәнең 3.8 пунктында күздә тотылган чорда әлеге Нигезләмәнең 3.5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырган гражданнар конкурста катнашуга кертелә.

3.3. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасына) карата квалификация таләпләренә җавап бирмәве, шулай ук Федераль законда билгеләнгән чикләүләренә бәйле рәвештә гражданин (граждан хезмәткәре) конкурста катнашуга кертелми.

Федераль законның 57 статьясының 1 өлешендәге 2 яисә 3 пунктында яки 59.1 статьясының 2 яисә 3 пунктында каралган дисциплинар йөкләмәсе булган граждан хезмәткәре Министрлыкта кадрлар резервына кертүгә конкурста катнашу өчен кертелми.

3.4. Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) өчен кандидатларга карата таләпләр дәүләт граждан хезмәте турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнде.

3.5. Россия Федерациясенең конкурста катнашырга теләк белдергән гражданины Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасына туры китерелгән формада шәхси гариза;

Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган формада тутырылган һәм имзаланган анкета, фото белән;

паспорт яки аны алмаштыра торган документ (тиешле документ конкурска килгәч шәхсән күрсәтелә) күчермәсе;

кирәкле һөнәри белем, квалификацияне һәм эш стажын раслаучы документлар:

хезмәт кенәгәсенең күчермәсе (хезмәт (эш) эшчәнлеге беренче тапкыр башкарыла торган очраклардан тыш), хезмәт (эш) урыны буенча нотариаль яки кадр хезмәте раслаган һәм (яки) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә

рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр һәм (яисә) гражданинның хезмәт (эш) эшчәнлеген раслаучы башка документлар;

белеме турында һәм квалификациясе турында документларның күчермәләре, шулай ук, ихтыяры буенча, өстәмә һөнәри белем алу нәтиҗәләре буенча квалификациясен күтәрүне яки бирелүне раслый торган документларның, фәнни дәрәҗә, фәнни исем бирелү турында документларның нотариаль яктан яки эш (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәсе;

гражданинда граждан хезмәтенә керү яисә аны узу өчен каршылык тудыручы авыруның булмавы турында документ;

Федераль законда, башка федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында каралган бүтән документлар.

3.6. Конкурста катнашу теләген белдергән, Министрлыкта граждан хезмәте вазыйфасын биләүче граждан хезмәткәре гаризаны министр исеменә тапшыра.

Бүтән дәүләт органында вазыйфа биләүче, конкурста катнашу теләген белдергән граждан хезмәткәре Министрлыкка министр исеменә шәхси гариза һәм үзе тутырган, имзалаган һәм үзе граждан хезмәтен били торган дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган, Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган формадагы анкетаны фотосын теркәп тапшыра.

3.7. Гражданинның (граждан хезмәткәренең) ризалыгы белән, гражданин (граждан хезмәткәре) биләп торуга дәгъва белдерә торган граждан хезмәте вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны үтәү андый белешмәләрне куллануга бәйле булса, дәүләт серен һәм закон нигезендә саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга рөхсәт рәсмиләштерү процедурасы үткәрелә.

Гражданинның министр исеменә тапшырылган белешмәләренең дөрес булу-булмавы тикшерелергә тиеш. Электрон рәвештә бирелгән белешмәләр Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә автоматлаштырылган рәвештә тикшерүгә дучар ителә.

3.8. Әлеге Нигезләмәнең 3.5 һәм 3.6 пунктларында күрсәтелгән документлар «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре) Министрлыкның рәсми сайтында, «Интернет» челтәрендә «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итүнең бердәм мәгълүмат системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – КС ИБМС) рәсми сайтында аларны кабул итү турында игълан урнаштырылган көннән соңгы 21 календарь көне эчендә кандидатлар тарафыннан Министрлыкка шәхсән, почта аша җибәреп яисә күрсәтелгән мәгълүмат системасыннан файдаланып, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә электрон рәвештә тапшырыла.

Документларны игътибарга лаек сәбәпсез вакытында тапшырмау, аларны тулы булмаган күләмдә яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданиннан (граждан хезмәткәреннән) аларны кабул итеп алудан баш тарту өчен нигез булып тора.

Хөрмәткә лаек сәбәп аркасында документларны үз вакытында тапшырмаганда, аларны тулы булмаган күләмдә яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшырганда министр аларны кабул итү вакытын күчерергә хокуклы.

## IV. КОНКУРС УЗДЫРУ МЕТОДИКАСЫ

4.1. Конкурсны үткәргәндә кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү методларына таянган, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган конкурс биремнәре һәм процедуралары кулланыла.

4.2. Конкурс процедуралары барышында кандидатларны бәяләү өчен түбәндәге бәяләү методлары кулланыла: тест, шәхси әңгәмә һәм анкеталау.

4.3. Кандидатларны чагыштыру һәм сайлап алу аларның конкурс биремнәрен үтәү һәм конкурс процедураларын үтү нәтиҗәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.4. Конкурс ике этапта үткәрелә.

4.4.1. Беренче этапта Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында, «Интернет» челтәрендәге КС ИБМС федераль дәүләт мәгълүмат системасы рәсми сайтында конкурста катнашу өчен документлар кабул итү турында игълан, шулай ук конкурс турында түбәндәге мәгълүматлар урнаштырыла:

- граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы аталышы;
- әлеге вазыйфаны биләү өчен квалификация таләпләре;
- граждан хезмәтен узу шартлары;
- тапшырылырга тиешле документларны кабул итү урыны һәм вакыты;
- күрсәтелгән документлар кабул ителә торган чор;
- конкурсны уздыруның күздә тотылган датасы;
- аны уздыру урыны һәм тәртибе;
- бәяләү методлары турында белешмәләр;
- граждан хезмәткәренең вазыйфаи регламентының вазыйфаи бурычларын, хокукларын һәм вазыйфаи бурычларны үтәмәгән (тиешенчә үтәмәгән) өчен җаваплылыгын үз эченә ала торган нигезләмәләре, граждан хезмәткәренең профессиональ хезмәт эшчәнлегендә файдалылык һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре;
- федераль порталда урнаштырылган беренчел текстка сылтама;
- башка мәгълүмат материаллары.

Конкурста катнашу өчен документлар кабул итү турында игълан һәм конкурс турында мәгълүмат шулай ук вакытлы басма матбугатта да бастырылырга мөмкин.

4.4.2. Тикшерү барышында федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары нигезендә гражданинның граждан хезмәтенә керүенә каршы килә торган шартлар ачыкланган очракта, аңа министр тарафыннан язмача рәвештә конкурста катнаштырудан баш тартуның сәбәпләре хакында хәбәр ителә.

Әгәр гражданин конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган булса, конкурста катнаштырудан баш тарту сәбәпләре хакында хәбәрләмә аңа, КС ИБМС системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә.

4.4.3. Вакантлы вазыйфаны биләү (кадрлар резервына кертү) өчен дәгъва белдергән, ләкин конкурста катнашуга кертелмәгән зат әлеге карарга Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять белдерергә хокуклы.

4.4.4. Министрлыкта граждан хезмәтенең бер вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасына) карата куелган квалификация таләп-

ләренә җавап бирә торган кимендә ике кандидатның булуы конкурсның беренче этабын төгәлләү шарты булып тора, бу хәл кандидатларны алга таба сайлау мөмкинлеген тәэмин итә.

Кандидатлар булмаса яки вазыйфага квалификация таләпләренә туры килә торган бер генә кандидат булса, конкурс узмаган дип таныла. Бу очракта бердәнбер кандидатка, кандидатларның таләп ителә торган саны булмау сәбәпле, конкурс үткәрелмәгән дип хәбәр ителә.

4.4.5. Конкурсның беренче этабы тәмамлангач министр конкурсның икенче этабын уздыру датасы (катнашу өчен документлар кабул итү тәмамланганнан соң 30 календарь көне узганчы), вакыты һәм урыны турында карар кабул итә. Дәүләт серен һәм закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга рөхсәт рәсмиләштерелгән очракта, конкурсның икенче этабын уздыру чорын министр билгели.

4.4.6. Конкурсның икенче этабы башланырга кимендә 15 календарь көне калганчы Министрлык «Интернет» челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында, «Интернет» челтәрендә КС ИБМС федераль дәүләт мәгълүмат системасы рәсми сайтында аны уздыру датасы, урыны һәм вакыты турында мәгълүмат, конкурста катнашуга кертелгән гражданнарның (граждан хезмәткәрләренең) исемлеген урнаштыра һәм тиешле хәбәрләрне язмача рәвештә кандидатларга җибәрә, бу очракта конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган кандидатларга, – «Интернет» челтәрендә КС ИБМС файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә.

Конкурс уздырылганда кандидатларга Россия Федерациясе Конституциясе һәм федераль законнар нигезендә хокуклар тигезлеге гарантияләнә.

Әгәр конкурс уздыру нәтиҗәсендә граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфаларын) биләү өчен квалификация таләпләренә җавап бирә торган кандидатлар ачыкланмаса, эшкә алучының вәкиле кабат конкурс уздыру турында карар кабул итәргә мөмкин.

4.4.7. Конкурсның икенче этабында түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын конкурс комиссиясе тарафыннан бәяләү;

Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурста җиңүчене билгеләү турында конкурс комиссиясе карары кабул ителә.

4.4.8. Конкурсны уздырганда конкурс комиссиясе кандидатларның профессиональ дәрәҗәсен алар тарафыннан тапшырылган белеме, граждан яки башка төрле дәүләт хезмәтен узуы, башка төрле хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыруы турындагы документлары нигезендә, шулай ук кандидатларның профессиональ һәм шәхси сыйфатларын бәяләү методлары: тест уздыру, шәхси әңгәмә һәм анкета уздыру нигезендә бәяли.

Министрлык тарафыннан конкурс комиссиясе эшчәнлеге, шулай ук кандидатлар тарафыннан конкурс процедураларын узу өчен тиешле оештыру һәм матди-техник шартлар тудырыла.

4.4.8.1. Тест уздыруны оештыру Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан Татарстан

Республикасы дәүләт органыннан Кадрларның бердәм мәгълүмат системасына килгән заявкалар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Тест уздыру өчен заявка Кадрларның бердәм мәгълүмат системасында конкурс комиссиясе утырышына кадәр кимендә ике атна калгач формалаштырыла.

Тест үткәрү Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүче гражданнарга тест үткәрү методикасын раслау турында» 2018 елның 8 июнендәге 25 номерлы карары белән расланган тест уздыру методикасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Түбәндәге конкурс процедураларында катнашуга кертү өчен кимендә 60 балл тупларга кирәк. Тест нәтиҗәләре Кадрларның бердәм мәгълүмат системасында чагылдырыла. Конкурс комиссиясе секретаре нәтиҗәләрне 10 баллы системага күчерү юлы белән рәсмиләштерә.

4.4.8.2. Тест үткән кандидатлар белән шәхси әңгәмәләр конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан үткәрелә. Конкурс комиссиясе утырышы барышында кандидат белән шәхси әңгәмә уздыру мәҗбүри булып тора.

Шәхси әңгәмә кандидатларның булачак һөнәри хезмәт итү эшчәнлеге темасы буенча конкурс комиссиясе әгъзаларының сорауларына бирелә торган җавапларыннан гыйбарәт, әңгәмә барышында конкурс комиссиясе кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын граждан хезмәте вазыйфасына һәм әлеге вазыйфа буенча вазыйфаи регламентның бүтән нигезләмәләренә карата тиешле квалификация таләпләреннән чыгып, шулай ук әлеге Нигезләмәгә һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте турындагы законнарында билгеләнгән башка нигезләмәләргә таянып бәяли. Шәхси әңгәмә барышында конкурс комиссиясе кандидат белән аның башка конкурс биремнәрен үтәү нәтиҗәләре хакында сүз алып бара, аның профессиональ дәрәҗәсен билгеләү максатында сораулар бирелә.

Шәхси әңгәмә уздыру кысаларында кандидатның профессиональ дәрәҗәсен бәяләүгә юнәлдерелгән сораулар бирелә.

Беренчел шәхси әңгәмә граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү буенча конкурс уздырыла торган структур бүлекчә җитәкчесе белән яки кадрлар резервына керү буенча конкурс уздырыла торган граждан хезмәте вазыйфалары төркеме буенча профессиональ хезмәт эшчәнлеге өлкәсе гамәлгә ашырыла торган структур бүлекчә җитәкчесе белән берлектә уздырылырга мөмкин.

Конкурс комиссиясе утырышына кадәр үткәргән очракта, беренчел шәхси әңгәмә уздыру нәтиҗәләре турында конкурс комиссиясе утырышы барышында аны үткәргән зат тарафыннан телдән доклад рәвешендә хәбәр ителә.

Конкурс комиссиясе тарафыннан шәхси әңгәмә уздырылганда министр карары нигезендә видеога һәм (яки) аудиога яздыру эше яки тиешле конкурс процедураларын уздыруның стенограммасы алып барыла, бу хәл, шул исәптән алга таба конкурс процедуралары барышында, аларны максималь объектив исәпкә алу өчен төрле кандидатларның бер үк сорауларга җавапларын һәм кабул ителүен чагыштыру мөмкинлеген бирә.

Кандидат белән шәхси әңгәмә тәмамланганнан соң конкурс комиссиясенең һәр

әгъзасы 2 нче кушымтага туры китерелгән формада төзелә торган конкурс бюллетененә, кирәк булганда конкурс комиссиясе әгъзасы тарафыннан кабул ителгән карарны нигезләүче кыскача дәлилләмә белән, кандидатны бәяләү нәтиҗәсен терки. Максималь балл 10 балл тәшкил итә. Минималь балл – 0 балл.

Кандидат белән конкурс комиссиясе тарафыннан кара-каршы шәхси әңгәмә уздырмыйча конкурста җиңүчене билгеләү турында конкурс комиссиясе карарын кабул итү рөхсәт ителми.

4.4.8.3. Анкета уздыру граждан хезмәтенең конкурс уздырыла торган вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервына кертү буенча конкурс уздырыла торган граждан хезмәте вазыйфалары төркеме) буенча вазыйфаи бурычлардан, шулай ук аталган вазыйфаларны биләү өчен квалификация таләпләреннән чыгып төзелгән сораулар нигезендә уздырыла.

Анкетага элегрәк гамәлгә ашырылган профессиональ эшчәнлек кысаларында вазыйфалар буенча үтәлә торган вазыйфаи бурычлар, профессиональ казанышлар, кандидат катнашкан чаралар (проектлар, форумнар, семинарлар һ.б.), басма матбугатларда аның мәкаләләре, мавыгулары турында, шулай ук кандидат тарафыннан тапшырылырга мөмкин булган тәкъдимнәр һәм (яки) турында тәкъдим хатлары турында сораулар кертелә.

Анкета кандидат тарафыннан шәхси әңгәмәне уздырыр алдыннан тутырыла. Кандидат сорауларга җавапларны үз-үзен презентацияләү рәвешендә әйтә.

Максималь балл 10 балл тәшкил итә. Минималь балл – 0 балл.

4.5. Кандидатның актыккы баллы итеп тест уздыру, шәхси әңгәмә уздыру һәм анкета уздыру нәтиҗәсендә конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан кандидатка куелган балларның уртача арифметик суммасы буларак билгеләнә. Максималь саны – 120 балл, минималь – 60 балл.

Кандидатларның ахыргы балларын чагыштыру нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе секретаре аларның йомгаклау балларын киметү тәртибендә кандидатлар рейтингын төзи.

4.6. Кандидатлар тарафыннан конкурс комиссиясе әгъзаларыннан тупланган тавышлар саны, кандидатлар тарафыннан дәгъва белдерелүче вазыйфа караган структур бүлекчә җитәкчесе фикере Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) өчен кандидат турында карар кабул итү һәм конкурска йомгак ясау өчен нигез булып тора.

Конкурс комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтасына туры китерелгән формада граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс йомгаклары буенча конкурс комиссиясе карары һәм әлеге Нигезләмәнең 4 нче кушымтасына туры китерелгән формада кадрлар резервына керүгә конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

Әлеге карар (беркетмә) туплаган балларын һәм конкурс комиссиясе тарафыннан бәяләү нәтиҗәләре буенча алар тарафыннан яуланган урыннарны күрсәтеп, кандидатлар рейтингын үз эченә ала.

4.7. Конкурс уздыру нәтиҗәсендә граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасы) буенча барлык кирәкле таләпләргә җавап бирә торган кандидатлар ачыкланган очракта, конкурс комиссиясе

өстәмә конкурс сынауларын үткәрү турында карар кабул итәргә яки яңа конкурс уздыру турында тәкъдим кертергә хокуклы.

4.8. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен конкурс нәтиҗәләре нигезендә конкурста җиңүчене граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләү турында министр боерыгы чыгарыла һәм аның белән хезмәт контракты төзелә.

Конкурс комиссиясе шулай ук тәкъдим холкына ия булган, граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү буенча конкурста җиңмәгән, ләкин профессиональ һәм шәхси сыйфатлары югары бәягә лаек булган кандидатны Министрлыкның кадрлар резервына кертү турында карар кабул итәргә хокуклы.

Кадрлар резервына конкурс комиссиясе тарафыннан тупланган балларының гомуми суммасы максималь баллның 60 процентыннан азрак булган кандидатлар арасыннан да кандидатлар тәкъдим ителергә мөмкин.

Кандидатның аны граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча кадрлар резервына кертүгә ризалыгы язмача формада яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында рәсмиләштерелә.

Граждан хезмәткәрен (гражданинны) – конкурста җиңүчене кадрлар резервына кертү, Министрлык боерыгы күчермәсен граждан хезмәткәренең шәхси эшенә теркәп, Министрлык боерыгы белән рәсмиләштерелә.

4.9. Конкурс нәтиҗәләре хакында хәбәрләр ул тәмамланганнан соң 7 көнлек чорда кандидатларга язмача рәвештә җибәрелә, бу очракта конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган кандидатларга, – «Интернет» челтәрендә КС ИБМС файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә.

Конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат шул ук чорда «Интернет» челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында һәм «Интернет» челтәрендә КС ИБМС рәсми сайтында урнаштырыла.

4.10. Кандидат конкурс комиссиясе карарына Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять бирергә хокуклы.

4.11. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) дәгъва белдергән, ләкин конкурста катнашуга кертелмәгән кандидатларның һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары язма гаризалары буенча конкурс тәмамланган көннән соң өч ел дәвамында аларга кайтарып бирелергә мөмкин. Әлеге чор тәмамланганчыга кадәр документлар Министрлык архивында саклана, аннан соң юкка чыгарылырга тиеш. Конкурста катнашу өчен электрон рәвештә тапшырылган документлар өч ел дәвамында саклана, шуннан соң бетерелергә тиеш.

4.12. Конкурста катнашу (конкурс үткәрү урынына бару һәм кире кайту, торак урынны наемга алу, яшәү, элемтә чаралары хезмәтеннән файдалану һ.б.) белән бәйле чыгымнар кандидатлар тарафыннан үз акчалары исәбеннән түләнә.

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмәгә 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы икътисад министрына

________________________________________
(министрның Ф.И.А.)

________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме)

________________________________________
(яшәгән урыны буенча адресы;

________________________________________
эш урыны, гариза тапшыру вакытына вазыйфасы)

________________________________________
(кесә телефоны, эл. почтасы)

Гариза

Мине Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) өчен конкурста катнашырга кертүне сорыйм, – түбәндәге Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен:

________________________________________________________________
(вазыйфа атамасы)

________________________________________________________________
(структур бүлекчә аталышы)

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмә белән, шул исәптән вакантлы вазыйфага карата билгеләнгән квалификация таләпләре белән, таныштым. Персональ белешмәләрнең «Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры китереп эшкәртелүенә риза.

Конкурс уздыру датасы һәм урыны турында e-mail яки күрсәтелгән кесә телефоны номерына СМС-хәбәр җибәрү ярдәмендә хәбәр алуга риза.

Гаризага түбәндәге документларны терким:

________________________________________________________________
(теркәлә торган документларны санап чыгарга)

| | | |
|---|---|---|
| ____________ | ______________ | ____________________ |
| (дата) | (имза) | (тулы имза) |

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмәгә 2 нче кушымта

Конкурс бюллетене

«__» ________ 20__ ел.
(конкурс уздыру датасы)

_______________________________________________________________________________
(аны биләү өчен конкурс уздырыла торган вазыйфаның тулысынча аталышы,

_______________________________________________________________________________
яки дәүләт органының кадрлар резервына кертү буенча конкурс уздырыла торган вазыйфалар төркеменең аталышы)

Шәхси әңгәмә уздыру нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе әгъзасы тарафыннан кандидатка бирелгән балл.

(Белешмә өчен: максималь балл ________ балл тәшкил итә)

| Кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме | Балл | Куелган баллга кыскача нигезләү (кирәк булганда) |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | |

_______________________________________________________ __________________
(конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме) (имзасы)

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмәгә 3 нче кушымта

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында
(дәүләт органы атамасы)

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс йомгаклары буенча конкурс комиссиясе
КАРАРЫ

«__» ________________________ 20__ ел.
(конкурс уздыру датасы)

1. Утырышта _____ конкурс комиссиясе әгъзасының ____ катнашты.

| Конкурс комиссиясе утырышында катнашкан конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме | Вазыйфа |
|---|---|
| | |
| | |
| | |

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздырылды

______________________________________________________________________
(дәүләт органының структур бүлекчәсен күрсәтеп, вазыйфаның аталышы)
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

3. Кандидатларны рейтинг буенча бәяләү нәтиҗәләре

| Кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме | Ахыргы балл | Рейтингтагы урыны (кими бару тәртибендә) |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |

4. Конкурста җиңүчене билгеләү буенча тавыш бирү нәтиҗәләре (барлык кандидатлар буенча тутырыла)

| |
|---|
| ______________________________________________________________<br>(рейтингта **беренче** урынны яулаган кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме) |

| Конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме | Тавыш бирү | | |
|---|---|---|---|
| | «хуплый» | «хупламый» | «тавыш бирмәде» |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| Җәмгысе | | | |

| (рейтингта **икенче** урынны яулаган кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме) | | | |
|---|---|---|---|
| Конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме | Тавыш бирү | | |
| | «хуплый» | «хупламый» | «тавыш бирмәде» |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| Җәмгысе | | | |

| (рейтингта **өченче** урынны яулаган кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме) | | | |
|---|---|---|---|
| Конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме | Тавыш бирү | | |
| | «хуплый» | «хупламый» | «тавыш бирмәде» |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| Җәмгысе | | | |

Тавыш бирү нәтиҗәләренә аңлатмалар (зарурлык булганда)

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

5. Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе киләсе кандидатны конкурста җиңүче итеп таный

| Җиңүче дип танылган кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме | Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы |
|---|---|
| | |

6. Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе түбәндәге кандидатларны кадрлар резервына кертүгә киңәш итә

| Дәүләт органының кадрлар резервына кертү өчен киңәш ителгән кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме | Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вазыйфалар төркеме |
|---|---|
| | |

7. Конкурс комиссиясе утырышында түбәндәге комиссия әгъзалары катнашмады

____________________________________________________________

(фамилия, исем, ата исеме)

____________________________________________________________

Конкурс комиссиясе рәисе ________________________________

(имза) (фамилия, исем, ата исеме)

Рәис урынбасары
конкурс комиссиясе ________ ___________________________

(имза) (фамилия, исем, ата исеме)

Конкурс комиссиясе секретаре ________ ___________________________

(имза) (фамилия, исем, ата исеме)

Конкурс комиссиясе әгъзалары ________ ___________________________

(имза) (фамилия, исем, ата исеме)

________ ___________________________

(имза) (фамилия, исем, ата исеме)

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмәгә 4 нче кушымта

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында
(дәүләт органы атамасы)
кадрлар резервына кертүгә конкурс нәтиҗәләре буенча
конкурс комиссиясе утырышы
БЕРКЕТМӘСЕ
«__» ________________________ 20__ ел.
(конкурс уздыру датасы)

1. Утырышта _____ конкурс комиссиясе әгъзасының ____ катнашты.

| Конкурс комиссиясе утырышында катнашкан конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме | Вазыйфа |
|---|---|
| | |
| | |
| | |

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең түбәндәге вазыйфалар төркеме буенча кадрлар резервына кертүгә конкурс уздырылды

______________________________________________________________________
(вазыйфалар төркеме атамасы)
______________________________________________________________________

3. Кандидатларны рейтинг буенча бәяләү нәтиҗәләре

| Кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме | Ахыргы балл | Рейтингтагы урыны (кими бару тәртибендә) |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

4. Кадрлар резервына кертү өчен кандидатны (кандидатларны) билгеләү буенча тавыш бирү нәтиҗәләре (бәяләү йомгаклары буенча максималь баллдан кимендә 60 процентын алган кандидатлар буенча тутырыла)

<table>
<tr><td colspan="4">______________________________________________<br>(рейтингта беренче урынны яулаган кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме</td><td colspan="3">Тавыш бирү</td></tr>
<tr><td>«хуплый»</td><td>«хупламый»</td><td>«тавыш бирмәде»</td></tr>
</table>

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |
| Җәмгысе | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| ______________________________<br>(рейтингта **икенче** урынны яулаган кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме) | | | |
| Конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме | Тавыш бирү | | |
| | «хуплый» | «хупламый» | «тавыш бирмәде» |
| | | | |
| | | | |
| Җәмгысе | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| ______________________________<br>(рейтингта **өченче** урынны яулаган кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме) | | | |
| Конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме | Тавыш бирү | | |
| | «хуплый» | «хупламый» | «тавыш бирмәде» |
| | | | |
| | | | |
| Җәмгысе | | | |

Тавыш бирү нәтиҗәләренә аңлатмалар (зарурлык булганда)

______________________________________________________________

______________________________________________________________

5. Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе кадрлар резервына кертү өчен түбәндәге кандидатны (кандидатларны) билгеле

| Дәүләт органының кадрлар резервына кертү өчен киңәш ителгән кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме | Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вазыйфалар төркеме |
|---|---|
| | |
| | |

6. Конкурс комиссиясе утырышында түбәндәге комиссия әгъзалары катнашмады

______________________________________________________________
(фамилия, исем, ата исеме)

______________________________________________________________

Конкурс комиссиясе рәисе ______________________________________
(имза) (фамилия, исем, ата исеме)

Конкурс комиссиясе
рәисе урынбасары ___________________________________________

(имза) (фамилия, исем, ата исеме)

Конкурс комиссиясе секретаре _________ ______________________________

(имза) (фамилия, исем, ата исеме)

Конкурс комиссиясе әгъзалары _________ ______________________________

(имза) (фамилия, исем, ата исеме)

_________ ______________________________

(имза) (фамилия, исем, ата исеме)